
Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучыларының нәфис басмасы

16 нчы гыйнвар, 2015 нче ел
№ 2

## Әлеге санда:



Тарих сәхифәләре ( 2нче бит)



Сәламәт тәндә– сәламәт акыл
( 3 нче бит)



Илһам канатында ( 4 нче бит)



### Яз килде

Нәүрүз житте, яз килде
Күктә кояшым көлде.
Сыерчыклар да кайтты
Яңа дөньяны уятты.

Тамчылар тып-тып тама
Йөрәкләргә моң сара
Язгы моң белән бергә
Жиргә яңарыш килә.

Яңгырлар жирне юа,
Үләннәр шытып чыга,
Жылы жилләр иркәләп,
Бөреләргә дәрт тула.

Гөрләвекләр агышы -
Яңа аваз табышы.
Төкле аягың белән
Кил син, яз, шатлык белән!

**Алсу Әхмәдуллина,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

# Тарих сәхифәләрендә






**Бөек Ватан сугышында илебез өчен баш салган җәлилчеләрне онытмыйбыз!**




## Җырларым

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.




Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

**Муса Җәлил**






# Сәламәт  тәндә — сәламәт акыл!



## Чаңгычылар  көне


1982 нче елның 28 нче февраленнән “Чаңгычы көне” билгеләнеп үтелә. Әлеге көнне спортсменнар һәм спортны сөючеләр чаңгыларга басып ярышалар.

Безнең мәктәп тә “Чаңгычы көн”ен уздырды. 5 нче сыйныфтан башлап барлык укучылар да бу көнне үзләренең көчләрен сынап карадылар. Спорт чараларын уздыру барлык кешеләрне дә сәламәтлекләре турында уйланырга  мәҗбүр итә. Әйе, чыннан да, сәламәтлек - ул кешедә булган иң зур байлык. Аны акчага да сатып алып булмый, туган көнгә  бүләк итеп тә булмый. Шуның өчен озак һәм бәхетле яшисең килсә, булган сәламәтлекне ныгыту, саклау турында кайгыртырга, үзеңнең өстеңдә бик күп эшләргә кирәк. Без яши торган дәвердә бу бигрәк тә актуаль булып тора. Ни өченме? Чөнки йогышлы авырулар, зарарлы гадәтләр  хәзерге көндә бик киң таралган, алар синең янда гына йөри. Аз гына да юлдан тайпылсаң, сине үзенең зәһәр кочагына алырга  көтеп тора. Телевизордан көн дә күрсәтелә торган  спиртлы эчемлекләр, тәмәке рекламасы шул юлга басуга бер этәргеч булып тора дип уйлыйм.



Шулай ук яшьләр арасында үзен зуррак, текәрәк итеп күрсәтер өчен, буш вакытын ни белән шөгыльләнергә белмәгән яки начар дусларга ияреп тәмәке тартып, исерткеч эчемлекләр, наркотиклар кулланучылар бар.

Спорт белән шөгыльләнгән кеше, минемчә, беркайчан да аракы да эчмәс, тәмәке дә тартмас, ә наркотик куллану турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Чөнки спорт белән дус кеше гел шат күңелле, күтәренке кәефтә була. Аның һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер торучы яхшы дуслары барлыкка килә. Ул үзе алдына максатлар куя һәм аларга ирешергә тырыша. Матур хыяллар белән яши. Ул тормышның ямен, гүзәллеген күрә белә, аннан ләззәт ала. Аның  инде начар эшләр эшләргә, начар гадәтләргә вакыты да, ихтыяҗы да калмый. Борынгы Грециядә бер таш кыяга: «Көчле буласың килсә - йөгер, сәламәт буласың килсә – йөгер!”, – дип язып куелган.



Әлеге сүзләрнең мәгънәсе бүген дә үзгәрмәгән. Халык та юкка гына: «Хәрәкәттә-бәрәкәт”, - дип әйтмәгән.Чыннан да спорт- начар гадәтләргә каршы бик көчле корал булып тора.

Безнең илебездә хәзер спортны үстерүгә зур әһәмият бирелә: спорт сарайлары, спорт мәйданчыклары, балаларга уен мәйданчыклары, хоккей кортлары салына, төзекләндерелә. Мәктәпләрдә физкультура дәресләре күбәйде, күп төрле ярышлар, кызыктыру чаралары  уздырыла. Алар безне сәламәт тормыш сайларга өнди!

**Гадел Якубов,**
**8 нче М сыйныфы укучысы**

# Илһам канатында




## Тукай

Язлар җиткән саен
Тукай иseме кабат яшәрә!
Еллар уза, ә шигырьләре һаман
Безне шулай алга дәшәләр.

Бишек җыры булып күңелләрдә
Өйрәтәләр илне сөяргә
Бар дөняга зур горурлык белән
Без бит татар халкы дияргә!

**Зәринә Хәмитҗанова,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**



## Яз

Яз җитте. Яз – табигатьнең кышкы уяну вакыты. Кар эри. Җирдән җырлый-җырлый челтерәп гөрләвекләр ага. Бозлар кузгала. Кошлар җылы яклардан кайталар. Сыерчыклар сайрыйлар. Көннәр дә озыная бара. Көннәр әле салкын, ләкин кояш көннән-көн күбрәк җылыта. Тиздән агачлар яфракларын ярачаклар.

Авылда язгы кыр эшләре башланыр. Җылы җилләр исә. Балалар, яз килүенә шатланып, гөрләвекләргә кечкенә көймәләрен җибәрәләр. Әкрен генә бар дөнья уяна: былтыргы үләннәр дә күренә, урамда кошлар сайравы ишетелә.

Яз – матур, шатлыкларга бай, күңелле вакыт. Әйдә, түрдән уз, яз!

**Снежанна Семенова,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**



**«Яз җитте»**
**Радик Идрисов,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**

**Җиңү көне**

Бүген 9 май!
Бүген Җиңү бәйрәме!
70 ел элек  бабаларыбыз
Фашистларны җиңә алды,
Аларга бүләккә — чәчәк бәйләме!
Әниемнең дәү этисе
Җиңеп кайткан сугыштан.
Аның орден, медальләрен
Әле дә саклыйм сандыкта,
Дәү этием сөйләп тора
Миңа һәр көн шул хакта.
Иминлек, тынычлык яшәсен!
Булмасын дөньяда сугышлар
Алар күргәнне без күрмик,
Тыныч булсын тормышлар!

**Ризван Загидуллин,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**



**“Очучы” Эль-Курди Юмна Тарек,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**




**Җиңү көне**

Бу сүзләрнең төгәл эчтәлеген, тулы мәгънәсен, чын җиңү хисен бүгенге көндә бары тик шул сугышта катнашкан ветераннарыбыз һәм сугыш ачысын тойган әби-бабайларыбыз гына беләдер, дип уйлыйм. Әлеге сугышта җиңү яулый алганнары өчен без дә алар белән бергә бәйрәм итәбез, аларның шатлыгын уртаклашабыз, аларга саулык-сәламәтлек телибез.

Нәрсә соң ул сугыш? Бу сорауга җавапны белмәвең яхшырак. Әмма ләкин бүгенге көндә дә сугышлар булып тора, кешеләр һәлак була, бер гөнаһсыз кешеләрнең тормышлары өзелә. Кемдер байлык өчен, кемдер көнләшүдән, кемдер үч белән, кемдер үзенең өстенлеген күрсәтергә теләп, кемдер үзен саклап калу өчен...

Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы гына да 27 миллионнан артык кешесен югалткан. Шул исәптән 4-5 миллион чамасы милләттәшләребез һәлак булган.

Бүген әлеге сугыш тәмамлануга 70 ел булачак. Әгәр сез Бөек Ватан сугышының ни икәнен белмисез икән - интернеттан эзләгез, укыгыз, сугышның чын йөзен күрегез. Киләчәктә шундый сугышларны булдырмыйк!

**Ильвина Садреева,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

# Илһам канатында





«Тыныч дөнья өчен рәхмәт, бабай!»
Дарья Андрякова,
5 нче Г сыйныфы укучысы

## *Тиздән Бек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтәчәкбез*

Җиңү килде җирне нурга күмеп,
Шатлык белән күзне чылатып.
Килде ул көн — горур күкрәкләрдә
Орден-медальләрне чыңлатып.

Хәтердән уела күп нәрсә,
Онытыла иң гүзәл яз, кышлар.
Онытылмый үзенең иңендә
Ил данын күтәргән язмышлар.

С.Сәүбәнова «Җиңү көне»

Кирәкми безгә кан коя,
Кирәкми безгә сугыш!
Безнең теләк якты, матур,
Тыныч хезмәт һәм тормыш.

Ә.Исхак «Кирәкми безгә сугыш»



«Җиңү бәйрәме белән!»
Ксения Федорова,
5 нче М сыйныфы укучысы




«9 май»
Дарья Кузягина,
5 нче Г сыйныфы укучысы



# Илһам канатында



***Бабаларыбыз Бөек Җиңүне нинди авырлыклар белән яулап алганын онытмагыз!***

***Илебез тыныч, күгебез аяз булсын, көннәребез бәхеттә үтсен!***

## Ант

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә — балам. Син әнкәсе анын,
Балабызны тотып ант итәм.
Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...
Бәлки, соңгы тапкыр — күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.
Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!» — ди ул күңеленнән,
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.
Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм.

**Фатих Кәрим**



## Кичер, илем!

Кичер мине, илем, синең бөек
Исмең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмәлмәдем
Бу тәнемне соңгы сулышта.
Юк, мин сине тузан
бөртегедәй
Сансыз гомрем өчен сатма-
дым.
Волхов шаһит: изге сугыш ан-
тын
Соң чиккәчә керсез сакладым.
Мин алдымда күрдем шыр
сөяктән
Котылгысыз үлем шәүләсен.
Кил син миңа, үлем, бары
гомрем
Коллык белән
төгәлләнмәсен!
Соңгы тамчы каным тамса
тамсын,
Тик антыма таплар кунма-
сын!»

**Муса Җәлил**





22 июнь. Таң атып килә. Авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләренең җылы куенында тәмле төшләр күреп нәни сабыйлар изрәп йоклыйлар. Шул вакытта канга туймас фашист этләре безнең чикне бозып авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоттылар. **Бөек Ватан сугышы** башланды.

**Сугыш ялкыны безнең дөньяны**
**Чолгап алмасын яңадан.**
**Сакла, сакла тынычлыкны,**
**Дан тынычлыкка, дан, дан, дан!**

# Мәктәп хәбәрләре

## Масленица

Масленица славяннарның кышны озатып, язны каршылау бәйрәме. Әлеге бәйрәм бик борынгы бәйрәмнәрнең берсе. Славяннар аны провославие динен кабул иткәнче үк билгели торган булганнар. Ул табигать көчләренә, ел вакытларына табыну белән бәйле булган. Әлеге йола җиде көн бәйрәм ителә. Бәйрәмнең төп атрибуты – түгәрәк коймак. Коймак – кояш символы, атна буена һәр гаиләдә әзерләнгән.



Безнең мәктәптә дә масленица гөрләп үтте. Барлык укучылар да тәмле-тәмле коймаклар пешереп килделәр. Һәр сыйныф үзенең өстәлен әзерләп, коймакларны сатты. Зурлары ун сум торсалар, кечкенәләре биш сумга бәяләнде.

Коймакларны саткан арада башкалар җырладылар, биеделәр.

Масленица бик күңелле һәм тәмле бәйрәм.



**Айгөл Марданова,**
**8 нче Г сыйныфы укучысы**







## Бәхетле мизгелләр

Бәхетле булуны ничек күз алдына китерәсез? Кайберәүләр аны байлыкта, югары даирәдә йөрүдә, матур итеп киенүдә күрә. Ә бүтәннәр исә — үзенең сәламәт булуында, тыныч тормышта яшәвендә, гаиләле булуында. Ә менә, мәсәлән, 2 нче Б һәм 4 нче Б сыйныфы укучылары, апалы-сеңелле, Әхмәдуллина Саида белән Кадрия өчен бәхет ул – алга омтылыш. Яхшы укулары өстенә әле алар һәр елны үткәрелә торган “Казан сандугачы” конкурсында урыннар алып киләләр. Районда 3 нче урынны алып, шәһәрдә узган этапта 2 нче урынга лаек булдылар.

Тормышта шундый зур максатлар алга куеп яшәү — зур нәрсә. Әлбәттә, кызларның уңган булуларында эти-әниләренең дә өлеше зур.

Безнең талантлы татар кызларына киләчәктә дә уңышлар теләп калабыз.

**Гөлмирә Батталова,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

## Ватанны саклау—зур бурыч!

Күптән түгел 23 февраль — Ватанны саклаучылар көне булып узды. Абыйлар, әтиләр, бабайлар бәйрәме ул. Алар безнең Туган илебезне, Бөек Ватан сугышы кырларында, Совет Армиясе сафларында саклаган… Бигрәк тә безнең малайларыбыз, егетләребез өчен истәлекле көн, чөнки иртәгә солдат булып, кулларына корал тотып, Ватаныбызны алар саклаячак. Аның өчен алар иң элек Туган илебезнең патриотлары булып үсәргә тиеш.

Безнең мәктәптә һәр сыйныф укучылары строй белән атлап, җыр җырлап күрсәттеләр. Аларны жюри әгъзәлары бәяләделәр. Әлеге чарада катнашкан сыйныфларга урыннар билгеләнде: 1 нче урынны – 5 нче Е-М, 6 нчы Г, 7 нче Г, 8 нче Г сыйныфы укучылары; 2 нче урынны – 5 нче М, 6 нчы М, 7 нче М, 8 нче А сыйныфы укучылары; 3 нче урынны – 5 нче А, 6 нчы А, 7 нче А сыйныфы укучылары яуладылар.



Әлеге чара балаларга патриотик тәрбия бирә. Ләкин патриотик тәрбия ул , строй белән йөрү генә түгел әле, ул үз милләтеңне, туган телеңне ярату да, өлкән буынга хөрмәт тә, халыклар дуслыгы да, спорт белән шөгыльләнү дә, рухи һәм физик тәрбия дә.

**Алсу Әхмәдуллина,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

# Эш беткәч, уйнарга ярый

## Яз ел фасылы турында сынамышлар



Беренче мартка кадәр кара карга күренсә, кар тиз китәр.

Март берендә аяз — аяз булыр бөтен яз.

Яз көне эретмичә озак тундырып торса, җәй коры була.

Май унберендә юеш булса, бөтен җәй юеш.

Көз озын килсә, яз соң килер.

Май егерме берендә яңгыр булса, көз яңгырлы булыр.

Беренче мартта көн җилле булса, бөтен җәй җилле булыр.

Унбишенче февральдә көн җылы булса, яз яхшы булла.

Апрель артык җылы булса, май салкын, җилле булыр.

Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшыга килә.

## Котлыйбыз!

78 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары ягымлы, кояшлы яз көннәренә туры килгән туган көннәрен билгеләп үтүче укытучыларын котлый:

**Гришина Татьяна Владимировна**
**Голованова Татьяна Васильевна**
**Рәхиева Әлфия Нәзгатовна**
**Гареева Светлана Александровна**
**Хәмидуллина Марзия Зәкиевна**
**Петрова Надежда Геннадьевна**
**Урманчеев Таһир Шамилевич**
**Шакирова Резеда Фаиковна**
**Коваленко Людмила Николаевна**
**Сибгатуллина Альбина Наилевна**
**Урманчеева Розалина Эльбрусовна**

**Тормыш юлларыгыз һәрчак балкып торсын,**
**Ягымлы, шат булсын күңелләрегез.**
**Озын гомер, бәхет-шатлык белән**
**Бер кайгысыз үтсен гомерләрегез!**



**Мөхәррирләр:** А. Әхмәдуллина, Г.Батталова, С. Семенова, И.Садреева, Э. Гибадуллина, И.Салахов, Р. Идрисов, А. Мәрданова.
**Консультант:** Л.И. Исмаилова

*Мәктәбем минем*

**Безнең адресыбыз:** ТР Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс: 268– 58-61
E– mail: https://edu.tatar.ru/priv/school78
**Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин:**
https://edu.tatar.ru/priv/school78/page813169.htm
**Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз:**
lyutsiya_906@mail.ru